# ТАТАР ТЕЛЕННӘН ЯҢА ФОРМАДА ДӘҮЛӘТ (ЙОМГАКЛАУ) АТТЕСТАЦИЯСЕ

АҢЛАТМА ҺӘМ КҮРСӘТМӘЛӘР

# ТАТАР ТЕЛЕННӘН ДЙА 2013 елда 3 төркемдә үткәрелә

- татар телендә гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары өчен (1 төркем);
- рус телендә гомуми белем бирү мәктәпләреннең татар төркемнәрендәге укучылар өчен (2 төркем);
- рус телендә гомуми белем бирү мәктәпләреннең рус төркемнәрендәге укучылары өчен (3 төркем).


# Биремнәрнең бүленеше


| | 1нче төркем | 2 нче төркем | 3 нче төркем |
|---|---|---|---|
| Беренче бүлек | С 1. Тыңланган текстның эчтәлеген язу (изложение – 70 сүз) | А1-А11 (сайлап алу тестлары) | В1,В2, А1-А6 - тыңлап аңлауга караган биремнәр |
| Икенче бүлек | А1-А7 (сайлап алу тесты) һәм В1-В9 (кыскача җавап язу) биремнәре | В1-В12 (кыскача җавап язу) биремнәре | А7-А17, В3 – укылган текстка нигезләнеп, тест эшләү |
| Өченче бүлек | С2 . Текстка нигезләнеп, сочинение язу (70 сүз) | С1. Текстка нигезләнеп, сочинение язу (100 сүз) | В4-В15 (кыскача җавап язу) биремнәре |
| Дүртенче бүлек | | | С1 – шәхси хат язу (70-80 сүз);<br>С2 - ситуациягә караган 5 реплика язу |

# Эшне башкару вакыты

- татар телендә гомуми белем бирү мәктәпләре  укучылары өчен – 240 минут;
- рус телендә гомуми белем бирү мәктәпләренең  татар төркемнәрендәге укучылар өчен – 240 минут;
- рус телендә гомуми белем бирү мәктәпләренең  рус төркемнәрендәге укучылары өчен – 150 минут.

# Бланк үрнәкләре





# А һәм В өлешендәге биремнәр турында мәгълүмат

- Барлык биремнәрнең дә дөрес җаваплары 1 балл белән бәяләнә*;
- Биремнәрнең саны төрле;
- Кыскача җавап язуга караган биремнәрдә җаваплар сан яки сүз, сүзтезмә белән языла;
- Биремнәр әзер җаваплар буенча тикшерелә.

* 3нче төркемнең B1, B2,B3 биремнәрендә һәр дөрес тәңгәллек өчен 1әр балл куела.

# С өлеше биремнәре турында

- С биремнәре  төрле: изложение, сочинение, шәхси хат, ситуацияләргә караган репликалар.
- С биремнәре махсус критерийлар буенча тикшерелә.

# ДЙА эшләрен тикшерү

- Эшнең А һәм В биремнәре компьютер  яки экспертлар тарафыннан әзер  җаваплар буенча тикшерелә;
- С биремнәрен экспертлар тикшерә

# С биремен тикшерү критерийлары турында

- С биремнәре текстның эчтәлегенә бәйле критерийлар һәм укучының грамоталылыгын  бәяләгән критерийларга нигезләнеп тикшерелә.
- Һәр критерий буенча балл куела, соңыннан аларның суммасы чыгарыла.

# Изложение

- Текст 2 тапкыр укыла;
- укучыдан микротемаларны (мәгънәви кисәкләрне) аерып чыгару сорала;
- укучының эше изложениенең эчтәлеге, башлангыч текстны җыйнакландыру, язманың бөтенлеге, бәйләнешле сөйләм, аның эзлеклелеге һәм грамоталылыкны билгеләү критерийларына нигезләнеп тикшерелә.

# Укучыга кайбер киңәшләр

**Текстның темасын ачыклагыз**, ягъни текстта сүзнең кем яки нәрсә турында булуын билгеләгез. Моны билгеләүдә сезгә текстның исеме, анда күп тапкыр кабатлана торган төп сүзләр, геройларның эш-гамәлләре, автор сүзләре ярдәм итә ала.

**Тексттан төп фикерне, идеяне табыгыз.** Ул һәрвакыт тема белән бәйле була. “Автор нәрсә әйтергә тели? Безне нәрсәгә өнди?” – дигән сорауларга җавап табу текстның төп фикерен, идеясен билгеләүгә китерә.

**Текстның стилен һәм сөйләм тибын ачыклагыз.** Әлеге гамәл текстны җыйнакландырганда кирәк булачак. Җыйнакландырылган тектта да автор стиле сакланырга тиеш. ( Мәсәлән, әдәби текстта башлам, вакыйгалар үстерелеше, кульминация һәм чишелеш бирелә; тасвирлама текст сөйләм предметы һәм аңа хас төп сыйфатларны аерып күрсәтү белән аерылып тора; фикерләмә текстта гомуми тезислар, аргументлар, дәлилләр һәм нәтиҗә бирелә).

Те**кстның микротемаларын ачыклагыз һәм язма өчен план төзегез**. Микротемалар, гадәттә, абзацлар саны белән тәңгәл килә. Алар тулы бер текстның кечкенә өлешләрен тәшкил итәләр һәм бер-берсенә бәйле булалар.

- Һәр микротеманы ачыклый торган сүзләр җыелмасын туплагыз.
- Һәр кызыл юлның төп фикерен ачыклагыз.
- Артык һәм кабатлана торган сүзләрне төшереп калдырып, һәр абзацны аерым-аерым формалаштырыгыз.
- Текстны тулы килеш укып карагыз. Кызыл юллар арасындагы бәйләнеш булуына, артык сүзләр булмауга игътибар итегез.

# Сочинение

- Текстның мәгънәсен аңлау, дәлил-мисалларның булуы, язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге, эшнең композицион төзеклеге һәм укучының грамоталылыгын бәяләү критерийлары буенча бәяләнә.
- С2К2-С2К4 критерийлары буенча 9 балл алырга мөмкин.
- Грамоталылыкны билгеләү критерийлары төрле.

# Укучыга кайбер киңәшләр

**1.Тексттагы төп проблеманы ачыклагыз.** “Автор нәрсә әйтергә тели? Сүз нәрсә турында бара?” кебек сораулар куеп карагыз. Текстның мәгънәсен аннан алынган цитата аша яки үз сүзләрегез белән аңлатып яза аласыз.

**2. Тексттан алда әйтелгән фикерегезне раслаган мисаллар табыгыз.** Үзегез күрсәткән проблеманы (төп теманы, фикерне) раслау өчен, тексттан 2 мисал табыгыз. Алар аерым сүзләр яки җөмләләр белән бирелергә мөмкин.

3. **Язманы логик яктан уйлап, бөтен текст итеп языгыз.** Сочинениенең эчтәлеге бөтен булырга, бәйләнешле сөйләм төзергә тиеш. Әлеге язма эштә ким дигәндә өч абзац булырга тиеш (1 – текстның мәгънәсен (темасын, проблемасын) ачыклау; 2- укучының автор позициясенә карата дәлилләре; 3) укучының үз фикере, нәтиҗәсе).

4. **Фикерегезне төгәл языгыз.** Язма эшнең композицион ягы төзек булу зарур. Язылган фикерләр төгәл әйтелергә, бер-берсе белән бәйле булырга тиеш.

5. **Сүзләрне дөрес языгыз.** Сочинение хәзерге татар әдәби теленең орфографик кагыйдәләренә буйсынып язылырга тиеш. Сүзнең язылышында шик туса, орфографик сүзлектән файдаланыгыз.

6. **Тыныш билгеләрен дөрес куегыз**. Тыныш билгеләрен дөрес куюыгызда шикләнсәгез, җөмләне башкача төзегез.

7. **Сүзләрне дөрес, төгәл, урынлы кулланыгыз.** Синоним, антоним, фразеологизмнарны урынлы кулланырга, диалекталь сүзләрдән качарга, язма сөйләм стилен сакларга кирәк.

8. **Язма сөйләм төгәл булсын.** Фактик хаталар булмасын, терминнарны дөрес кулланыгыз.

# Шәхси хат

- Бирелгән темага карата, сорауларга җавап биреп,  дуска хат язуны сорый.
- Бирем коммуникатив бурычны үтәү, текстны оештыру,  текстның лексик-грамматик төзелеше һәм грамоталылыкны билгеләү критерийлары буенча тикшерелә.

# Укучыга кайбер киңәшләр

- **Биремне игътибар белән укыгыз.** Терәк хаттагы сорауларны ачыклагыз.
- **Хатның башлам өлешен языгыз.** Башлам өлешендә исәнләшү була, хатны язучының исеме әйтелә, хәлләре турында сорала, алынган хат өчен рәхмәт белдерелә.
- **Терәк хаттагы мәгълүматка фикерегезне белдерегез.** Андагы мәгълүматны сылтама буларак файдаланыгыз.
- **Терәк хаттагы сорауларга җавап языгыз.** Җавабыгызда шулай ук терәк хаттагы  гыйбарәләрне куллана аласыз.
- **Хатыгызны йомгаклагыз.** Йомгак өлешендә үз сорауларыгызны да яза аласыз. Саубуллашырга, җавап хаты көтүегезне белдерергә онытмагыз. Шулай ук  хатның кемнән булуын (үз исемегезне) һәм хат язылу көнен күрсәтергә кирәк.

# Сөйләм ситуациясенә караган репликаны язу

- Укучыга 5 ситуация тәкъдим ителә.
- Һәр ситуация язылган репликаның эчтәлеге һәм грамоталылык критерийлары буенча тикшерелә.

# Грамматик хаталар

- Хаталы сүзтезмә ( өч *балалар*)
- Сүз төркемнәрен дөрес ясый/ төрләндерә белмәү (*шатлы*, *бунын...)*
- Җөмләләрне дөрес төземәү
- Туры сөйләмне дөрес кулланмау
- Җөмлә чикләрен дөрес билгеләмәү

# Сөйләм хаталары

- Сүзләрнең мәгънәсен аңламыйча куллану
- Синонимнарны, фразеологизмнарны дөрес кулланмау
- Гади сөйләм сүзләрен урынсыз куллану
- Плеоназм (артык сүз куллану)
- Тамырдаш сүзләрне янәшә куллану
- Синтаксик бөтеннәрнең ярлылыгы.

# Өстәмәләр

- Грамоталылыкны бәяләү вакытында укучы язмасының күләме искә алына.
- Язма норма күләмнең  яртысыннан кимрәк булса, 0 балл куела, эш үтәлмәгән булып санала.
- Язма норманың яртысын гына тәшкил итсә, 1 балл гына куела.

# КИРӘКЛЕ МӘГЪЛҮМАТЛАРНЫ ТҮБӘНДӘГЕ СЫЛТАМА БУЕНЧА ТАБА АЛАСЫЗ:

http://mon.tatarstan.ru/rus/kontr_izmer_mater.htm